# КАРАР

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Сорочьи Горы, Кама поселогы авыл торак пунктларында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2020 елның 17 ноябре № 1

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2020 елның 17 ноябрендә "2021елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Сорочьи Горы, Кама поселогы авыл торак пунктлары территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә торып укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан гайре, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен:

- Олы Елга, Сорочьи Горы авылларындагы су этем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

- авыл җирлеге торак пунктларында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

- Олы Елга авылында Мөхәммәтгали урамындагы юлларны ремонтлауга (асфальт грануляты сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, асфальт гранулятны җәюгә, эшләр өчен түләүгә);

-Казаклар авылында Яр буе урамында (вак таш сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, вак ташны җәюгә, эш өчен түләүгә);

-Сорочьи Горы авылының Прикамская, Пролетарская, Садовая-1,Садовая-2 урамнарында (асфальт грануляты сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, асфальт гранулятны җәюгә , эшләр өчен түләүгә);

- авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап торуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);

- Казаклар авылында Горная урамындагы инеш аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлауга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Олы Елга авылы зираты территориясен киртәләүгә (тотып алуга) (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Олы Елга авылындагы Молодежная урамында тышкы суүткәргеч салуга (220 см тирәнлектә траншея казуга, 63 мм диаметрлы торбаларны сузуга, траншеяны күмүгә, янгын гидранты урнаштыруга);

- Казаклар авылында контейнер мәйданчыклары ясауга һәм җиһазландыруга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Казаклар авылында каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен 5 данә контейнер сатып алуга

тотуга Сез ризамы?“ мәсьәләсебуенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены йомгаклары турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенәсайлау хокукына ия 66 җыенда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 55 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 55кеше;

“Юк” позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены **карар кылды**:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Сорочьи Горы, Кама поселогы авыл торак пунктларындагы гражданнар җыенын **узган дип**, гражданнар җыены нәтиҗәләрен **дөрес дип** танырга.

2.“2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Сорочьи Горы, Кама поселогы авыл торак пунктлары территорияләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә торып укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан гайре, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен:

- Олы Елга, Сорочьи Горы авылларындагы су этем скважиналары өчен тирәнлек насослары сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

- авыл җирлеге торак пунктларында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);

- Олы Елга авылында Мөхәммәтгали урамындагы юлларны ремонтлауга (асфальт грануляты сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, асфальт гранулятны җәюгә, эшләр өчен түләүгә);

-Казаклар авылында Яр буе урамында (вак таш сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, вак ташны җәюгә, эш өчен түләүгә);

-Сорочьи Горы авылының Прикамская, Пролетарская, Садовая-1,Садовая-2 урамнарында (асфальт грануляты сатып алуга, аны ташу буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә, асфальт гранулятны җәюгә , эшләр өчен түләүгә);

- авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын карап торуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);

- Казаклар авылында Горная урамындагы инеш аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлауга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Олы Елга авылы зираты территориясен киртәләүгә (тотып алуга) (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Олы Елга авылындагы Молодежная урамында тышкы суүткәргеч салуга (220 см тирәнлектә траншея казуга, 63 мм диаметрлы торбаларны сузуга, траншеяны күмүгә, янгын гидранты урнаштыруга);

- Казаклар авылында контейнер мәйданчыклары ясауга һәм җиһазландыруга (материал сатып алуга, шартнамә буенча эш өчен түләүгә);

- Казаклар авылында каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен 5 данә контейнер сатып алуга

Тотуга Сез ризамы?“ мәсьәләсе буенча карарны **кабул ителгән** дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4.Карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы Ф.А.Садриев